Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы Майская Горка авыл җирлеге составына керүче Трудовой торак пунктында

ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

2023 елның 17 ноябре № 2

«Россия Федерация сендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы Майская Горка авыл җирлегенең Трудовой торак пунктында гражданнар җыены КАРАР БИРДЕ:

1. Түбән Кама муниципаль районының Майская Горка авыл җирлеге Трудовой торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, 1 төркем инвалидлар, Бөек Ватан сугышы ветераннары һәм катнашучыларыннан, Бөек Ватан сугышы ветераннарының тол хатыннарыннан, көндезге уку формасы буенча белем алучы студентлар һәрби хезмәттәге, контракт буенча, мобилизацияләнгән гражданнар һәм аларның гаилә әгъзаларыннан тыш 2024 елда 1000 сум күләмендә үзара салым кертергә, ә 2 нче төркем инвалидлар, 80 яшьтән өлкәнрәк пенсионерлар һәм күп балалы гаиләләр өчен гражданнар җыены карарында билгеләнгән сумманың 50 (илле) проценты күләмендә билгеләргә.

2. Тынычлык, Домостроителей, Совет урамнарында юлларны төзекләндерүгә (материалларны сатып алу һәм китерү (вак таш, гравий, асфальтобетон, яисә асфальтобетон катнашмасы) тигезләү һәм тыгызлау эшләрен башкару, килешү буенча эшләр өчен түләү) юнәлдерергә.

Гражданнар җыенындарәислекитүче
Майская Горка авыл җирлеге башлыгы А.П. Морозов